ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «15» декабреннән № 281

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфа окладлары күләмен арттыру һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының бюджет өлкәсендәге хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2025 елның 5 сентябрендәге 181 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең хакын тәртипкә китерү һәм социаль гарантияләрне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 ноябрендәге 996 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» карары белән билгеләнгән тәртиптә, бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмаган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмен 2026 елның 1 гыйнварыннан арттырырга.

2. Бюджет өлкәсенең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен, әлеге карарның 1 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджет өлкәсенең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый

торган муниципаль берәмлекләрдәге бюджет өлкәсендәге аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи окладының күләмен 1,1 мәртәбә индексацияләргә һәм аны 16 928,0 сум күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов